БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
15 марта 2021 г.

**КАРАР**
№ 43

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы иҗтимагый Советы турында Нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән иҗтимагый берләшмәләр һәм башка коммерциягә карамаган оешмалар арасында үзара хезмәттәшлекне тәэмин итү өчен Балтач муниципаль районы Советы карар бирде:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы иҗтимагый Советы турында Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе

Р. Р. Нотфуллин

Татарстан Республикасы
Балтач район Советының
2021 елның «15» март
43 номерлы карарына
1 нче кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Балтач муниципаль районы иҗтимагый советы (алга таба – Иҗтимагый совет) - үз эшчәнлеген иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашыручы даими рәвештә киңәш бирүче һәм консультатив орган булып тора.

1.2. Иҗтимагый совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына һәм боерыкларына, Балтач муниципаль районы Уставына, Балтач муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Иҗтимагый совет Россия Федерациясе гражданнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм башка коммерциягә карамаган оешмалар вәкилләре эшчәнлегендә ирекле катнашу нигезендә төзелә.

1.4. Иҗтимагый совет эшчәнлеге ачыклык һәм хәбәрдарлык принципларында гамәлгә ашырыла.

## 2. ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТНЫҢ МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

2.1. Иҗтимагый совет булдыру максаты – муниципаль район халкының ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алу, гражданлык җәмгыяте үсеше принципларын тормышка ашырганда, шулай ук җирле үзидарә органнары, муниципаль оешмалар, башка муниципаль органнар һәм оешмалар эшчәнлегенә җәмәгать контролен гамәлгә ашырганда иҗтимагый берләшмәләр һәм башка коммерцияле булмаган оешмаларның Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары (алга таба - җирле үзидарә органнары) белән хезмәттәшлеген тәэмин итү.

2.2. Иҗтимагый советның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- Балтач муниципаль районы территориясендә гамәлдә булган муниципаль программаларны тормышка ашыруга гражданнарны, иҗтимагый берләшмәләрне һәм башка коммерциягә карамаган оешмаларны җәлеп итү;

- җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне карауда катнашу, Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлеге мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр эшләү;

- кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм коммерциягә карамаган башка оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау максатларында, җирле үзидарә органнары һәм муниципаль оешмалар, федераль законнар нигезендә аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы башка муниципаль органнар һәм оешмалар эшчәнлегенә җәмәгать контролен гамәлгә ашыру;

- гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү мәсьәләләре буенча муниципаль норматив хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза үткәрү.

## 3. ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТ ВӘКАЛӘТЛӘРЕ

3.1. Иҗтимагый совет үзенә йөкләнгән бурычларны гамәлгә ашыру өчен түбәндәгеләрне эшләргә хокуклы:

- федераль законнар нигезендә аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнарында, муниципаль оешмаларда, башка органнарда һәм оешмаларда, дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматлардан һәм федераль законнар белән чикләнгән мәгълүматтан тыш, мәгълүматны соратып алырга;
- федераль һәм республика законнары нигезендә җәмәгать контролен гамәлгә ашырырга;
- гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү мәсьәләләре буенча муниципаль норматив хокукый актлар проектларына җәмәгать экспертизасы үткәрергә;
- җирле үзидарә органнарына җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча хокукый җайга салуны камилләштерү, Балтач муниципаль районы (шәһәре) территориясендә җирле үзидарә оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр җибәрергә;
- гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнарына тәкъдимнәр кертергә;
- Иҗтимагый совет, комиссияләр һәм эш төркемнәре утырышларына җирле үзидарә органнары, муниципаль оешмалар, федераль законнар нигезендә аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы башка органнар һәм оешмалар вәкилләрен иҗтимагый совет утырышларына чакырырга;
- Татарстан Республикасы Балтач район Советы утырышларында, шулай ук аның даими комиссияләре эшендә катнашырга;
- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен кулланып, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары аша үз эшчәнлекләре нәтиҗәләре турында муниципаль район халкына хәбәр итәргә;
- җирле үзидарә органнары алдында муниципаль бүләкләр белән бүләкләү турында үтенечнамә бирергә;
- Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары һәм муниципаль норматив хокукый актлар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга.

## 4. ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТ ВӘКАЛӘТЛӘРЕ ВАКЫТЫ ҺӘМ АНЫ ФОРМАЛАШТЫРУ ТӘРТИБЕ

4.1. Иҗтимагый совет 18 кешедән тора.

4.2. Иҗтимагый совет әгъзаларының вәкаләтләре вакыты 5 ел тәшкил итә һәм Иҗтимагый советның беренче утырышы уздырылган көннән исәпләнә. Яңа составтагы Иҗтимагый советның беренче утырышы уздырылганнан соң, алдагы составтагы Иҗтимагый совет әгъзаларының вәкаләтләре туктатыла.

Иҗтимагый совет әгъзаларының вәкаләтләре Иҗтимагый совет тарафыннан үз-үзен таркату турында карар кабул ителгән очракта вакытыннан алда туктатыла. Әлеге карар билгеләнгән сандагы Иҗтимагый совет әгъзаларының кимендә өчтән бере инициативасы буенча билгеләнгән сандагы Иҗтимагый совет әгъзаларының кимендә өчтән икесе булган күпчелек тарафыннан кабул ителә.

4.3. Иҗтимагый берләшмәләр һәм башка коммерциягә карамаган оешмалар бер кандидатны тәкъдим итәргә хокуклы.

4.4. Балтач муниципаль районы (шәһәре) башлыгы билгеләнгән сандагы Иҗтимагый совет әгъзаларына кандидатларның яртысын тәкъдим итә.

Иҗтимагый совет билгеләнгән сандагы Иҗтимагый совет әгъзаларына кандидатларның яртысын тәкъдим итә. Иҗтимагый советны башлангыч формалаштырганда Иҗтимагый берләшмәләр һәм башка коммерциягә карамаган оешмалар билгеләнгән сандагы Иҗтимагый Совет әгъзаларына кандидатларның яртысын тәкъдим итә.

Балтач муниципаль районы башлыгы тарафыннан күрсәтелгән санда Иҗтимагый совет әгъзалары тәкъдим ителмәсә, Иҗтимагый совет составына кертү өчен документлар кабул итү срогы тәмамланган көннән соң 10 көн узгач, кандидатларны тәкъдим итү хокукы Иҗтимагый советка күчә.

4.5. Иҗтимагый совет составын формалаштыру максатыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Балтач муниципаль районының рәсми сайтында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында Иҗтимагый совет составын формалаштыру процедурасы башлануы турында хәбәрнамә урнаштырыла.

Хәбәрнамәдә Иҗтимагый совет әгъзаларына кандидатлар буенча тәкъдимнәр җибәрү вакыты һәм адресы күрсәтелгән булырга тиеш. Тәкъдимнәрне кабул итү вакыты хәбәрнамәне урнаштырганнан соң 15 көннән дә ким һәм 30 көннән дә артык булмаска тиеш.

Иҗтимагый советның гамәлдәге составы вакытында, вәкаләтләре беткәнче өч айдан да соңга калмыйча хәбәрнамә урнаштырылырга тиеш.

Күрсәтелгән срокта Иҗтимагый совет составына кандидатлар Балтач муниципаль районы башлыгына яки Иҗтимагый советка түбәндәге документларны тапшыралар:

- Иҗтимагый советка кертү турында гариза-анкета;
- иҗтимагый берләшмәләрдән, коммерциягә карамаган оешмалардан яки инициативалы төркемнәрдән  чыгуны раслаучы документлар (беркетмәләр) (иҗтимагый берләшмәләрдән, коммерциягә карамаган оешмалардан яисә инициативалы төркемнәрдән тәкъдим ителгән очракта).

Әгәр кабул итүнең билгеләнгән чоры узганнан соң Иҗтимагый совет әгъзаларына кандидатлар саны әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән Иҗтимагый совет әгъзалары саныннан ким булса, Балтач муниципаль районы башлыгы, Иҗтимагый совет әгъзаларына кандидатларны өстәмә рәвештә тәкъдим итү максатыннан, күрсәтелгән чорны 15 көннән дә артмаган вакытка озайта.

Документларны кабул итү тәмамланганнан соң 30 көн эчендә Иҗтимагый советны формалаштыру процедурасы башкарыла.

Иҗтимагый Совет әгъзасына кандидат, Иҗтимагый совет әгъзасы буларак расланганчы теләсә кайсы вакытта, Балтач муниципаль районы башлыгына язмача гариза юллап, Иҗтимагый совет әгъзасы итеп раслауга ризалыгы турында гаризасын кире алырга хокуклы. Бу очракта кандидат Иҗтимагый совет әгъзаларына кандидатлар исемлегеннән төшереп калдырыла.

Иҗтимагый советның шәхси составы Балтач муниципаль районы башлыгы карары белән Иҗтимагый совет формалашу вакыты тәмамланганнан соң 10 көн эчендә формалаша һәм раслана.

Иҗтимагый совет составы расланганнан соң 3 көн эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Балтач муниципаль районының рәсми сайтында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырыла.

4.6. Түбәндәгеләр тарафыннан Иҗтимагый совет әгъзаларына кандидатлар тәкъдим итү рөхсәт ителми:

1) сәяси партияләр, аларның региональ һәм җирле бүлекләре тарафыннан;

2) «Экстремистик эшчәнлеккә каршы тору турында» 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, экстремистик эшчәнлекне гамәлгә ашыруның ярамавы турында язма рәвештә кисәтү ясалган иҗтимагый берләшмәләр, башка коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан - кисәтү чыгарылган көннән алып бер ел эчендә, суд тарафыннан законсыз дип танылмаган булса;

3) Әгәр суд тарафыннан туктатылу турында карар законсыз дип табылмаса, эшчәнлеге федераль закон нигезендә туктатылган иҗтимагый берләшмәләр һәм башка коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан.

## 5. ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТ ӘГЪЗАСЫНЫҢ СТАТУСЫ, ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

5.1. Иҗтимагый совет әгъзасы итеп Балтач муниципаль районы территориясендә даими яшәүче, 18 яшькә җиткән Россия Федерациясе гражданы билгеләнә ала.

5.2. Түбәндәгеләр Иҗтимагый совет әгъзалары була алмый:

1) суд тарафыннан хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикләнгән дип танылган затлар;

2) кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем ителүе булган затлар;

3) ике ил гражданлыгы булган затлар;

4) дәүләт хакимияте органнарында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләгән затлар, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатлары.

5.3. Иҗтимагый совет әгъзалары Иҗтимагый совет, аның комиссияләре һәм эшче төркемнәре эшендә шәхсән катнашалар. Карар кабул иткәндә Иҗтимагый советның башка әгъзасына тавыш бирү хокукын тапшыру рөхсәт ителми.

5.4. Иҗтимагый совет әгъзасы түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Иҗтимагый совет, Иҗтимагый советның комиссияләре һәм эшче төркемнәре эшчәнлегенең теләсә кайсы мәсьәләсе буенча үз фикерләрен ирекле рәвештә белдерергә;

2) Иҗтимагый совет эше турында мәгълүматы булган документларны, башка материалларны алырга;

3) Иҗтимагый совет утырышының көн тәртибе буенча тәкъдимнәр кертергә, аларның утырышларына материаллар, Иҗтимагый совет карарлары проектларын әзерләүдә катнашырга, утырышларның көн тәртибе мәсьәләләре буенча фикер алышуда катнашырга;

4) Иҗтимагый совет карары белән килешмәгән очракта, телдән һәм язмача белдерергә, бу Иҗтимагый совет утырышы беркетмәсендә билгеләп үтелә һәм аңа карата әлеге фикер әйтелгән карарга беркетеп бирелә;

5) Иҗтимагый совет карарларын гамәлгә ашыруда катнашырга.

5.5. Иҗтимагый совет әгъзалары үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда аларны тәкъдим иткән иҗтимагый берләшмәләр һәм башка коммерциягә карамаган оешмалар карарлары белән бәйле булырга тиеш түгел.

5.6. Иҗтимагый совет әгъзасы үз эшчәнлеген иҗтимагый советта сәяси партияләр, иҗтимагый берләшмәләр һәм башка коммерциягә карамаган оешмалар мәнфәгатьләрендә, шулай ук шәхси мәнфәгатьләрдә кулланырга хокуклы түгел.

5.7. Иҗтимагый совет әгъзасын аны тәкъдим иткән иҗтимагый берләшмә һәм коммерциягә карамаган оешма тарафыннан чакыртып алу рөхсәт ителми.

5.8. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла:

1) аның вәкаләтләре чоры тәмамлану, шулай ук Иҗтимагый совет тарафыннан үз-үзен таркату турында карар кабул итү;

2) Иҗтимагый совет составыннан чыгу турында гариза бирү;

3) аны хокукый сәләтсез дип тану;

4) аның үлеме;

5) аңа карата чыгарылган судның гаепләү карарының законлы көченә керүе;

6) аның этика кодексы нормаларын бозуы - Иҗтимагый палата утырышында кабул ителгән, билгеләнгән сандагы Иҗтимагый совет әгъзаларының кимендә яртысы карары буенча;

7) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату яисә ике ил гражданлыгын алу;

8) Иҗтимагый совет утырышлары эшендә җитди сәбәпсез системалы (өч тапкырдан артык) катнашмау;

9) Балтач муниципаль районыннан читкә даими яшәү урынына китү.

Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату турында карар Иҗтимагый совет утырышында кабул ителә һәм Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре туктатылу датасы күрсәтелгән Иҗтимагый совет карары белән рәсмиләштерелә.

5.9. Иҗтимагый совет әгъзасы Иҗтимагый совет рәисе кул куйган Совет әгъзасы таныклыгына ия. Иҗтимагый совет рәисе таныклыгына Балтач муниципаль районы башлыгы кул куя.

Таныклыкның үрнәге һәм тасвирламасы Балтач муниципаль районы башлыгы күрсәтмәсе белән раслана.

## 6. ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТ ЭШЧӘНЛЕГЕН ОЕШТЫРУ

6.1. Яңа составтагы Иҗтимагый совет үзенең беренче утырышына Иҗтимагый совет составы расланганнан соң 30 көннән дә соңга калмыйча җыела.

Иҗтимагый советның беренче утырышы Иҗтимагый совет инициативасы буенча чакырыла.

6.2. Иҗтимагый совет утырышлары кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла.

6.3. Иҗтимагый совет карарлары Иҗтимагый совет әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

6.4. Иҗтимагый совет карарлары тәкъдим итү характерында була.

Җирле үзидарә органнары, муниципаль оешмалар, федераль законнар нигезендә аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы башка муниципаль органнар һәм оешмалар, аларга җибәрелгән карарларны, җәмәгат контроле нәтиҗәләре буенча әзерләнгән йомгаклау документларын карый һәм аларны алган көннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча, ә кичектереп тору мөмкин булмаган очракларда - кичекмәстән, Иҗтимагый советка нигезле җаваплар җибәрә.

6.5. Иҗтимагый совет үз эшен Иҗтимагый совет рәисе күрсәтмәсе буенча Иҗтимагый совет утырышларында расланган планнар нигезендә оештыра.

Иҗтимагый совет эшен планлаштыру Иҗтимагый совет әгъзалары, Иҗтимагый совет рәисе һәм җирле үзидарә органнары тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашырыла.

6.6. Иҗтимагый совет эшчәнлегенең төп формалары булып Иҗтимагый совет утырышлары, тыңлаулар һәм иң мөһим проблемалар буенча «түгәрәк өстәлләр», муниципаль район (шәһәр) халкын сораштыру, форумнар, семинарлар һәм законнарга каршы килми торган башка эшчәнлек формалары.

6.7. Иҗтимагый советның чираттан тыш утырышы Иҗтимагый совет рәисе карары буенча яисә билгеләнгән сандагы Иҗтимагый совет әгъзаларының кимендә өчтән бер өлеше инициативасы буенча чакырылырга мөмкин.

6.8. Әгәр Иҗтимагый совет утырышында билгеләнгән сандагы Иҗтимагый советның әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, ул тулы хокуклы дип санала.

6.9. Иҗтимагый совет эшендә Балтач муниципаль районы башлыгы һәм аның урынбасарлары, Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе һәм аның урынбасарлары, Балтач район Советы депутатлары, җирле үзидарә органнарының башка вазыйфаи затлары, шулай ук Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы аппараты хезмәткәрләре катнаша ала.

6.10. Иҗтимагый совет әгъзалары үз составларыннан күпчелек тавыш белән ачык тавыш бирү юлы белән Иҗтимагый совет рәисен сайлыйлар. Иҗтимагый совет рәисен вазыйфасыннан азат итү мәсьәләсе Иҗтимагый Советның вәкаләтләре чоры тәмамлангач карала, шулай ук Иҗтимагый совет тарафыннан аларның шәхси гаризасы яисә Иҗтимагый Советның барлык әгъзалары санының биштән бере тәкъдиме буенча да карала.

Иҗтимагый совет рәисе:

1) Иҗтимагый советның чираттагы утырышы көн тәртибе проектын төзи һәм аны үткәрү датасын билгели;

2) чираттагы яисә чираттан тыш утырыш уздыру турында Иҗтимагый совет әгъзаларына хәбәр итә;

3) Иҗтимагый совет эшчәнлеге мәсьәләләре буенча гарызнамәләр җибәрә;

4) иң мөһим мәсьәләләр буенча тыңлаулар, комиссияләр һәм эшче төркемнәр утырышлары үткәрү турында карар кабул итә;

5) Иҗтимагый совет әгъзаларының этика кодексын эшли һәм Иҗтимагый советка раслауга тапшыра;

6) үз эшчәнлеге турында Иҗтимагый советка хисап бирә;

7) Иҗтимагый совет карары буенча башка вәкаләтләрне башкара.

Иҗтимагый совет Рәисе булмаганда, аның вәкаләтләрен Иҗтимагый совет Рәисе карары буенча Иҗтимагый совет әгъзаларының берсе башкара.

6.11. Иҗтимагый совет әгъзалары үз составларыннан күпчелек тавыш белән ачык тавыш бирү юлы белән Иҗтимагый совет секретарен сайлыйлар.

Иҗтимагый совет секретаре:

1) Иҗтимагый совет, комиссияләр, эшче төркемнәр утырышының көн тәртибе проектларын һәм аларның утырышлары беркетмәләре проектларын әзерли;

2) Иҗтимагый советның агымдагы эшчәнлеген оештыра;

3) Иҗтимагый совет әгъзаларына иҗтимагый совет утырышының вакыты, урыны һәм көн тәртибе, шулай ук Иҗтимагый совет эшенең расланган планнары турында хәбәр итә;

4) җирле үзидарә органнары белән үзара бәйләнештә, Иҗтимагый советның көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләре буенча Иҗтимагый совет утырышларына мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләүне тәэмин итә;

5) Иҗтимагый совет Рәисе кушуы буенча үзенең компетенциясе чикләрендә башка мәсьәләләрне хәл итә.

Иҗтимагый совет секретаре булмаган очракта, аның вазыйфаларын Иҗтимагый совет Рәисе кушуы буенча Иҗтимагый совет әгъзаларының берсе башкара.

6.12. Иҗтимагый совет карарлары бәяләмәләр, тәкъдимнәр һәм мөрәҗәгатьләр, шулай ук аның эшчәнлегенең оештыру һәм башка мәсьәләләре буенча карарлар рәвешендә кабул ителә.

Иҗтимагый советның бәяләмәләре, тәкъдимнәре һәм мөрәҗәгатьләре тәкъдим итү характерында була һәм күпчелек тавыш белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

Иҗтимагый советның оештыру һәм башка мәсьәләләр буенча карарлары Иҗтимагый совет әгъзалары өчен мәҗбүри характерга ия һәм, әгәр әлеге Нигезләмәдә башкасы каралмаган булса, ачык тавыш бирү юлы белән күпчелек тавыш белән кабул ителә.

Тавышлар тигез булганда, Иҗтимагый совет Рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

6.13. Иҗтимагый совет гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү мәсьәләләре буенча муниципаль норматив хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза үткәрергә хокуклы.

Иҗтимагый экспертиза нәтиҗәләре буенча Иҗтимагый совет бәяләмәләре тәкъдим итү характерында була һәм җирле үзидарә органнарына җибәрелә.

6.14. Иҗтимагый совет закон нигезендә гражданнарның, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка коммерциягә карамаган оешмаларның граждан инициативалары турында мәгълүматын җыюны һәм эшкәртүне башкара.

Иҗтимагый совет иҗтимагый тормышның актуаль мәсьәләләре буенча гражданнар форумнары, тыңлаулар һәм башка чаралар оештыра һәм үткәрә.

Иҗтимагый совет гражданнарга һәм иҗтимагый берләшмәләргә, гражданнарның башка берләшмәләренә тәгъдим ителгән граждан инициативалары турында мәгълүмат җиткерә.

6.15. Иҗтимагый совет ел саен муниципаль район территориясендә граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында доклад әзерли.

Иҗтимагый советның еллык доклады җирле үзидарә органнарына һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына җибәрелә.

Иҗтимагый советның еллык доклады Татарстан Республикасы Балтач район Советы утырышында тыңлана.

Иҗтимагый советның еллык докладындагы тәкъдимнәр җирле үзидарә органнары эшендә кулланылырга мөмкин.

6.16. Иҗтимагый совет юридик зат булып тормый.

## 7. ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫ ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ ОЕШМАЛАР, ФЕДЕРАЛЬ ЗАКОННАР НИГЕЗЕНДӘ АЕРЫМ ГАВАМИ ВӘКАЛӘТЛӘРНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКА ОРГАННАРЫ ҺӘМ ОЕШМАЛАРЫ ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ ҖӘМӘГАТЬ КОНТРОЛЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРГАНДА ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

7.1. Иҗтимагый совет «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда каралган формаларда һәм тәртиптә җәмәгать контролен гамәлгә ашыра.

7.2. Җәмәгать контролен гамәлгә ашырганда иҗтимагый совет түбәндәгеләргә хокуклы:

1) җәмәгать контролен гамәлгә ашырганда үткәрелә торган чараларны оештыручы, башлап җибәрүче (инициатор) буларак чыгыш ясарга, шулай ук үткәрелә торган чараларда катнашырга;

2) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җирле үзидарә органнарыннан, муниципаль оешмалардан, федераль законнар нигезендә аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Балтач муниципаль районының башка органнарыннан һәм оешмаларыннан, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр булган мәгълүматтан, шәхси мәгълүматлар турында белешмәләрдән һәм федераль законнар белән файдалану мөмкинлеге чикләнгән мәгълүматлардан тыш, җәмәгать контролен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

3) федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль норматив хокукый актларда каралган очракларда һәм тәртиптә җирле үзидарә органнарына һәм муниципаль оешмаларга, федераль законнар нигезендә аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Балтач муниципаль районының башка органнарына һәм оешмаларына барырга;

4) иҗтимагый контрольне гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча йомгаклау документын әзерләргә һәм аны җирле үзидарә органнарына һәм муниципаль оешмаларга, федераль законнар нигезендә аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Балтач муниципаль районының башка органнарына һәм оешмаларына, массакүләм мәгълүмат чараларына карау өчен җибәрергә;

5) кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка дәүләт коммерциягә карамаган оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу фактлары ачыкланган очракта, федераль законнар нигезендә җәмәгать контролен гамәлгә ашыру барышында алынган материалларны Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә һәм прокуратура органнарына җибәрергә;

6) федераль законнарда каралган очракларда билгесез затлар даирәсенең хокукларын, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка дәүләтнеке булмаган коммерциягә карамаган оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау өчен судка мөрәҗәгать итәргә;

7) Россия Федерациясе законнарында, Татарстан Республикасы законнарында, муниципаль норматив хокукый актларда каралган башка хокуклардан файдаланырга.

7.3. Җәмәгать контролен гамәлгә ашырганда иҗтимагый совет түбәндәгеләргә бурычлы:

1) җәмәгать контроле турында Россия Федерациясе законнарын һәм Татарстан Республикасы законнарын үтәргә;

2) җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә бәйле федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне үтәргә;

3) җирле үзидарә органнарының, муниципаль оешмаларның, федераль законнар нигезендә аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Балтач муниципаль районының башка органнарының һәм оешмаларның законлы эшчәнлегенә каршылыклар тудырмаска;

4) әгәр аның таралуы федераль законнар белән чикләнгән булса, җәмәгать контролен гамәлгә ашыру барышында алынган мәгълүматның конфиденциальлеген сакларга;

5) «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җәмәгать контролен гамәлгә ашыру буенча үз эшчәнлеге һәм контроль нәтиҗәләре турында мәгълүматны халыкка җиткерергә;

6) федераль һәм республика законнарында каралган башка вазыйфаларны башкарырга.

## 8. ЙОМГАКЛАУ ҺӘМ КҮЧМӘ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

8.1. Иҗтимагый Советның урнашу урыны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Балтач муниципаль районындагы "Наз" халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәге" дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе бинасында

8.2. Иҗтимагый совет эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итү җирле үзидарә органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8.3. Әлеге Нигезләмә рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.